# Миләш тә бит бергә тәлгәшләнә

Быел көзләр озын булып килде,

Тәлгәшләнеп утыра миләшләр.

Яфраклары очкан еракларга,

Миләшләргә җилләр сердәшләр.

Миләшләрнең кызыл тәлгәшләре,

Коелырлар салкын җирләргә.

Соңгы яфраклары сау бул диеп,

Кушылып китәр алар җилләргә.

Яфракларга охшап арабыздан,

Китмәсеннәр дуслар, кордашлар.

Миләш тә бит бергә тәлгәшләнә,

Тормыш шулай ямле дус-ишләр.

Кыска көннәр, озын төннәрендә,

Моңсулана безнең йөрәкләр.

Миләшләрдәй бергә нык булырга,

Раббым бирсә иде терәкләр.

*Мехаматнур Нәҗметдинов, 16.10.2021*